**СОВЕТ
АЗЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д. 22,
с. Азеево, 423190

**ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢАЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АКЪЯР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ**
Совет урамы,22 йорт
Акъяр авылы, 423190

тел.: (8-84348) 3-71-31, факс: (8-84348)3-7-61, Azeev.Nsm@tatar.ru

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль
районы Акъяр авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

2026 елның 24 нче феврале

№ 6-20

«Җирле салым суммалары өлешендә бурычны түләттереп булмый дип тану өчен өстәмә нигезләр билгеләү турында» 2023 елның 14 ноябрендәге 39-124 номерлы Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акъяр авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясының 3 пунктына һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акъяр авыл җирлеге Уставына ярашлы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акъяр авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акъяр авыл җирлеге Советының 2023 елның 14 ноябрендәге 39-124 номерлы «Җирле салымнар буенча түләнергә мөмкин булмаган бурычны тану өчен өстәмә нигезләр билгеләү турында»гы карарына (ТР Яңа Чишмә муниципаль районы Акъяр авыл җирлеге Советының 2024 елның 14 июнендәге 46-143 номерлы; 2025 елның 29 декабрендәге 4-15 номерлы;) (алга таба Карар дип атала) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарның 1 нче пунктының 1 нче пунктчасы түбәндәгечә язылсын:
«1) физик затның үлеме яки үлем турында игълан ителгән көннән өч еллык чор тәмамлану, Россия Федерациясе гражданлык-процессуаль законнарында билгеләнгән тәртиптә (закон белән билгеләнгән очраклардан тыш) һәм Россия Федерациясе Салым кодексының 59 нчы статьясының 1 нче пунктының 3 нче пунктчасында күрсәтелгән очракларда»;

1.2. Карарның преамбуласыннан түбәндәге сүзләрне алып ташларга: «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы »;

2. «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акъяр авыл җирлеге Советының 2023 елның 14 ноябрендәге 39-124 номерлы «Җирле салым суммалары буенча түләнергә мөмкин булмаган бурычны тану өчен өстәмә нигезләр билгеләү турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында»гы 2025 елның 29 декабрендәге 4-15 номерлы карарын гамәлдән чыгарырга.

3. Бу карар 2026 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга: https://pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында: https://novosheshminsk.tatarstan.ru

5. Бу карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә
муниципаль районы Акъяр
авыл җирлеге башлыгы урынбасары Н.Р.Давлетшин